ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасында умартачылыкны үстерү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 25 ноябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә умартачылык турында» 2020 елның 30 декабрендәге 490-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында умартачылыкны үстерү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Умартачылыкны үстерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Умартачылыкны үстерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Умартачылыкны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Умартачылыкны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) умартачылыкны үстерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) умартачылыкны үстерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм башкаруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

**4 статья. Умартачылыкны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

1. Умартачылыкны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) умартачылыкны үстерүгә юнәлдерелгән чаралар каралган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең умартачылыкны үстерү өлкәсендәге вәкаләтле органын билгеләү;

3) бал кортлары авыруларын кисәтү һәм бетерү һәм аларны дәвалау чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

4) умарталыкның ветеринария-санитария паспортын рәсмиләштерү һәм алып бару тәртибен билгеләү;

5) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 3 – 5 пунктларында күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан яисә аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (органнары) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**5 статья. Умартачылыкны үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, аларга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә умартачылыкны үстерү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирелгән очракта, күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

**6 статья. Умартачылыкны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме**

1. Умартачылыкны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме Федераль законның 9 статьясында каралган юнәлешләр буенча тәэмин ителә һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары чикләрендә күрсәтелә.

2. Умартачылыкны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру шартлары һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

7 статья. **Умартачылыкны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәме принциплары**

Умартачылыкны үстерү өлкәсендә дәүләт ярдәменең төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) умартачылыкны гамәлгә ашыручы физик һәм юридик затларның, дәүләт ярдәме күрсәтүне сорап, гариза белән мөрәҗәгать итү тәртибе;

2) умартачылыкны гамәлгә ашыручы физик һәм юридик затларның дәүләт ярдәменнән бертигез дәрәҗәдә файдалануы;

3) дәүләт ярдәме күрсәтү процедураларының ачык булуы;

4) дәүләт ярдәмен, Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәп, күрсәтү.

8 статья. **«Татарстан Республикасында умартачылыкны дәүләт тарафыннан җайга салу һәм аңа дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында**

«Татарстан Республикасында умартачылыкны дәүләт тарафыннан җайга салу һәм аңа дәүләт ярдәме турында» 2010 елның 22 ноябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 11) үз көчен югалткан дип танырга.

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2021 ел, 11 декабрь
№ 94-ТРЗ